**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«14» 05 2024 ел Яр Чаллы №1179

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында «Яр Чаллы – Водозабор» автомобиль юлын реконструкцияләү, км 1+462 – км 2+102» объекты буенча территорияне планлаштыру проектына һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «2022 һәм 2023 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм күрсәтелгән проектларга иҗтимагый фикер алышулар яки халык тыңлаулары үткәрмичә үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 17 январендагы 14 номерлы карары, «Главтатдортранс» дәүләт казна учреждениесенең проектка төзәтмәләр кертү турында 2024 елның 22 апрелендәге 2209 номерлы мөрәҗәгате нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында «Яр Чаллы – Водозабор» автомобиль юлын реконструкцияләү, км 1+462 – км 2+102» объекты буенча территорияне планлаштыру проектына һәм ызанлау проектына (2022 елның 24 августындагы 2303 номерлы, 2024 елның 13 мартындагы 667 номерлы үзгәрешләр белән) 16:39:021201:4719 кадастр номерлы җир кишәрлеген 16:39:021201:6813 һәм 16:39:021201:6814 кадастр номерлы җир кишәрлекләренә бүлү өлешендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин